ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**БИЛГЕЛӘМӘСЕ**

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең 9.11 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин П.П. Апышков шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

Казан шәһәре 2020 елның 24 гыйнвары

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданин П.П. Апышков шикаятен алдан өйрәнгән судья Ф.Р. Волкова бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин П.П. Апышков Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең (алга таба шулай ук — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Акчалата түләүләр бирү тәртибе турындагы нигезләмә),

гариза бирүче мөрәҗәгать иткән вакытта гамәлдә булган редакциясендә, 9.11 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Акчалата түләүләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең 9.11 пункты буенча, пенсионерларның мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсен бәяләгәндә аларның гаилә әгъзалары исәпкә алынмаганлыгы билгеләнгән.

Шикаятьтән, аңа өстәмәдән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документларның күчермәләреннән күренгәнчә, гражданин П.П. Апышков пенсионер һәм элегрәк җәмәгать транспортында йөрү өчен айлык акчалата түләү алган. Әмма аңа бу түләү туктатылган. Әлеге түләүнең туктатылу сәбәпләрен ачыклау максатыннан ул Казан шәһәренең Совет районындагы Республика матди ярдәм үзәге бүлекчәсенә мөрәҗәгать иткән, аның җавабыннан аңлашылганча, түләүне туктату Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына 2019 елның 1 апреленнән үз көченә кергән үзгәрешләр белән бәйле, алар нигезендә аның мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе билгеләнгән иң чик күрсәткечтән артыграк — 40 квадрат метр. Пенсионерның мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсен бәяләгәндә аның гаилә әгъзалары исәпкә алынмый.

Гражданин П.П. Апышков билгеләгәнчә, күрсәтелгән Татарстан Республикасы Законына кушымтадан һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарыннан чыгып, пенсионерларның мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсен бәяләгәндә алар ике категориягә бүленгән: гаилә әгъзалары белән бергә яшәгән пенсионерлар һәм ялгыз пенсионерлар.

Аның фикеренчә, дәгъва белдерелә торган нигезләмә пенсионерларның мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсен бәяләү тәртибенә билгесезлек кертә. Шикаять белдерелә торган норма, мөрәҗәгать итүче күрсәткәнчә, асылда, пенсионерларның мөлкәт белән тәэмин ителешен бәяләгәндә аларның өченче категориясен кертә — гаилә әгъзалары булуы исәпкә алынмаган

пенсионерлар. Шул ук вакытта, гражданин П.П. Апышков санаганча, аларга карата ялгыз пенсионерлар өчен түгел, ә гаилә әгъзалары белән бергә булган пенсионерлар өчен билгеләнгән мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе кулланыла. Аның раславынча, бу пенсионерларның мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен бәяләгәндә аларны дискриминацияләү булып тора. Шуңа бәйле рәвештә ул гаилә законнары нигезендә уртак хуҗалык алып баручы ире, хатыны, ата-анасы, балалары гаилә әгъзалары дип танылуына, ә гаилә мәсьәләләре дәүләт яклавында булуына игътибар итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Конституция судыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең 9.11 пунктын Татарстан Республикасы Конституциясенең 13, 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 38 (беренче өлеш) һәм 54 (беренче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы икенче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды конституциячел суд эшләрен башкарганда гамәлдәге норматив хокукый актларның конституциячеллеген тикшерә. Татарстан Республикасы Конституция судында эш карала башлаганчы яки аны карау чорында юкка чыгарылган яисә үз көчен югалткан актларның конституциячеллеген тикшерү мөмкин түгел (Татарстан Республикасы Конституция судының 2010 елның 27 февралендәге 3-О номерлы, 2014 елның 17 сентябрендәге 15-О номерлы һәм 2017 елның 6 февралендәге 6-О номерлы билгеләмәләре).

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карарына

үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 10 декабрендәге 1131 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән Акчалата түләүләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең дәгъва белдерелә торган 9.11 пункты яңа редакциядә бәян ителгән. Югарыда аталган карар 2019 елның 16 декабрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) басылып чыккан. Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган Акчалата түләүләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең 9.11 пункты нормасы мөрәҗәгать итү вакытына гамәлдә булган редакциясендә үз көчен югалткан һәм кулланылырга тиеш түгел.

Россия Федерациясе Конституция Суды билгеләп үткәнчә, норматив хокукый актны әлеге актны кабул иткән дәүләт хакимияте органы тарафыннан гамәлдән чыгару мондый актның гамәлдә булырга тиеш булмаган буларак бәяләнүен ачык күрсәтә, шул ук вакытта әлеге дәүләт хакимияте органы таяна торган сәбәпләр конституциячел суд эшчәнлеге максатлары өчен әһәмиятле түгел (2013 елның 4 июнендәге 882-О номерлы Билгеләмә).

Шулай итеп, үз көчен югалткан Акчалата түләүләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең дәгъва белдерелә торган 9.11 пункты Татарстан Республикасы Конституция судында конституциячел суд эшчәнлеге тәртибендә карау предметы була алмый, ә гражданин П.П. Апышковның бу өлештә шикаяте карала алмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пунктына һәм икенче өлешенә, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73, 100 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары белән расланган Татарстан

Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең 9.11 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин П.П. Апышков шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки ул «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының билгеләнгән таләпләре нигезендә карала алмый.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданин П.П. Апышковка һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре» ндә һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) басылып чыгарга тиеш.

**№ 3-О**

**Татарстан Республикасы**
**Конституция суды**